| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2017 Казан ш. № 6-187/тп

«Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә газдан файдалану җайланмасын технологик ялгау буенча 2018 елга түләү зурлыгын билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкалары билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бәяләрен, аны транспортлаштыру хезмәтләренә тарифларны һәм газдан файдалану җайланмасын Россия Федерациясе территориясендә газ бүлү челтәрләренә технологик ялгау өчен түләүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2000 елның 29 декабрендәге 1021 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең «Газдан файдалану җайланмасын газ бүлү челтәрләренә технологик ялгау өчен түләү күләмен һәм аның зурлыгын билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкаларын раслау турында» 2014 елның 28 апрелендәге 101-э/3 номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Сәгатенә максималь газ сарыфы 500 куб. метр һәм азрак һәм (яисә) ялганучы газүткәргечендә проект буенча эш басымы 0,6 МПа һәм азрак булган газдан файдалану җайланмасын «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә технологик ялгау очраклары өчен, шушы карар кушымтасына туры китереп, технологик ялгау буенча түләү зурлыгын билгеләү өчен файдаланыла торган стандартлаштырылган тариф ставкалары билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 нче пунктында билгеләнгән стандартлаштырылган

тариф ставкалары 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2017 № 6-187/тп карарына кушымта

# Сәгатенә максималь газ сарыфы 500 куб. метр һәм азрак һәм (яисә) ялганучы газүткәргечендә проект буенча эш басымы 0,6 МПа һәм азрак булган газдан файдалану җайланмасын «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә технологик ялгау очраклары өчен 2018 елга технологик ялгау буенча түләү зурлыгын билгеләү өчен файдаланыла торган стандартлаштырылган тариф ставкалары

(НДС исәпкә алмыйча)

| № п/п | Шартлы билгелә-неше | Стандартлаштырылган тариф ставкасының аталышы | Үлчәү берәмлеге | Ставка күләме |
|---|---|---|---|---|
| 1 | С1* | Газ бүлү оешмасының төзелә (үзгәртеп корыла) торган газ бүлү челтәреннән җир кишәрлеге чигеннән газ бүлү оешмасының газ бүлү челтәренә кадәр туры линия буенча исәпләнүче озынлык 150 метрдан артык булган очраклар өчен проект документациясе әзерләүгә бәйле чыгымнарын каплау буенча стандартлаштырылган тариф ставкалары | сум | 282 975 |
| 2 | С2* | Газ бүлү оешмасының төзелә (үзгәртеп корыла) торган газ бүлү челтәреннән җир кишәрлеге чигеннән газ бүлү оешмасының газ бүлү челтәренә кадәр туры линия буенча исәпләнүче озынлык 150 метр һәм аннан азрак тәшкил иткән очраклар өчен проект документациясе әзерләүгә бәйле чыгымнарын каплау буенча стандартлаштырылган тариф ставкалары | сум/м$^3$ 1 сәгатькә | 2980,0 |
| 3 | С3** | Газ бүлү оешмасының корыч газүткәргеч төзүгә (үзгәртеп коруга) бәйле чыгымнарын каплау буенча, төзелә (үзгәртеп корыла) торган газ бүлү челтәреннән җир кишәрлеге чигеннән газ бүлү оешмасының газ бүлү челтәренә кадәр туры линия буенча исәпләнүче озынлык 150 метрдан артык булган очраклар өчен файдаланыла торган стандартлаштырылган тариф ставкасы | | |
| 3.1 | | Газүткәргечне җирдән (җир өслегеннән) уздыру, түбәндәге диаметрлар диапазанонында: | | |
| 3.1.1 | | 158 мм һәм кыскарак | сум/чм | 245 000 |
| 3.1.2 | | 159-218 мм | сум/чм | 339 000 |
| 3.1.3 | | 219-272 мм | сум/чм | 454 000 |
| 3.1.4 | | 273-324 мм | сум/чм | 552 000 |
| 3.1.5 | | 325-425 мм | сум/чм | 617 000 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3.1.6 | | 426-529 мм | сум/чм | 878 000 |
| 3.1.7 | | 530 мм һәм күбрәк | сум/чм | 1268000 |
| 3.2 | | Газүткәргечне җир астыннан уздыру, түбәндәге диаметрлар диапазонында: | | |
| 3.2.1 | | 158 мм һәм кыскарак | сум/чм | 327 000 |
| 3.2.2 | | 159-218 мм | сум/чм | 493 000 |
| 3.2.3 | | 219-272 мм | сум/чм | 667 000 |
| 3.2.4 | | 273-324 мм | сум/чм | 869 000 |
| 3.2.5 | | 325-425 мм | сум/чм | 1003 000 |
| 3.2.6 | | 426-529 мм | сум/чм | 1448 000 |
| 3.2.7 | | 530 мм һәм күбрәк | сум/чм | 1556 000 |
| 4 | С4** | Газ бүлү оешмасының полиэтилен газүткәргеч төзүгә (үзгәртеп коруга) бәйле чыгымнарын каплау буенча, төзелә (үзгәртеп корыла) торган газ бүлү челтәреннән җир кишәрлеге чигеннән газ бүлү оешмасының газ бүлү челтәренә кадәр туры линия буенча исәпләнүче озынлык 150 метрдан артык булган очраклар өчен файдаланыла торган стандартлаштырылган тариф ставкасы | | |
| 4.1 | | Полиэтиленнан салынган газүткәргеч, түбәндәге диаметрлар диапазонында: | | |
| 4.1.1 | | 109 мм һәм кыскарак | сум/чм | 225 000 |
| 4.1.2 | | 110-159 мм | сум/чм | 288 000 |
| 4.1.3 | | 160-224 мм | сум/чм | 308 000 |
| 4.1.4 | | 225-314 мм | сум/чм | 467 000 |
| 4.1.5 | | 315-399 мм | сум/чм | 584 000 |
| 4.1.6 | | 400 мм и выше | сум/чм | 784 000 |
| 5 | С5** | Газ бүлү оешмасының барлык диаметрлардагы, төрле материаллы трубаралардан һәм төрле типта уздырыла торган газүткәргечләр төзүгә (үзгәртеп коруга) бәйле чыгымнарын каплау буенча, төзелә (үзгәртеп корыла) торган газ бүлү челтәреннән җир кишәрлеге чигеннән газ бүлү оешмасының газ бүлү челтәренә кадәр туры линия буенча исәпләнүче озынлык 150 метр һәм азрак тәшкил иткән очраклар өчен файдаланыла торган стандартлаштырылган тариф ставкасы | сум/$м^3$ 1 сәгатькә | 468,0 |
| 6 | С6** | Газ бүлү оешмасының газкөйләү пунктлары төзүгә (үзгәртеп коруга) бәйле чыгымнарын каплау буенча стандартлаштырылган тариф ставкасы | сум/$м^3$ 1 сәгатькә | 1943 |
| 7 | С7** | Газ бүлү оешмасының катодлы яклау станцияләре төзүгә (үзгәртеп коруга) бәйле чыгымнарын каплау буенча стандартлаштырылган тариф ставкасы | сум/$м^3$ 1 сәгатькә | 2933 |
| 8 | С8* | Газ бүлү оешмасының мөрәҗәгать итүче тарафыннан техник шартлар үтәлүен һәм мөрәҗәгать итүченең капиталь төзелеш объектларын газ бүлү челтәренә фактик тоташтыруның (технологик ялгауның) һәм газ җибәрүнең гамәлгә ашырылуын тикшерүгә бәйле чыгымнарын каплауга стандартлаштырылган тариф | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | ставкасы (С8) | | |
| 8.1 | | Корыч газүткәргечләр, түбәндәге диаметрлар диапазонында: | | |
| 8.1.1 | | 158 мм һәм кыскарак | сум | 29 444 |
| 8.1.2 | | 159-218 мм | сум | 29 725 |
| 8.1.3 | | 219-272 мм | сум | 30 511 |
| 8.1.4 | | 273-324 мм | сум | 32 705 |
| 8.1.5 | | 325-425 мм | сум | 33 078 |
| 8.1.6 | | 426-529 мм | сум | 34 639 |
| 8.1.8 | | 530 мм и выше | сум | 37 440 |
| 8.2 | | Полиэтилен газүткәргечләр, түбәндәге диаметрлар диапазонында: | | |
| 8.2.1 | | 109 мм һәм кыскарак | сум | 28 399 |
| 8.2.2 | | 110-159 мм | сум | 28 399 |
| 8.2.3 | | 160-224 мм | сум | 28 680 |
| 8.2.4 | | 225-314 мм | сум | 28 963 |
| 8.2.5 | | 315-399 мм | сум | 28 963 |
| 8.2.6 | | 400 мм и выше | сум | 29 334 |

Искәрмә:
* С1, С2, С8 стандартлаштырылган тариф ставкалары хәзерге бәяләрдә билгеләнде.
** С3-С7 стандартлаштырылган тариф ставкалары 2001 ел бәяләрендә билгеләнде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге